ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРУССИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.16в, с. Старые
Уруссу, 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 16в йорт, Иске
Урыссу авылы, 423960

Тел.:(85593) 4-42-31, факс:4-42-10, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№** 20 2021 елның 20 декабре

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2022 елга муниципаль контроль буенча закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 7 санлы карары белән кабул ителгәнТатарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2022 елга муниципаль контроль буенча закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалауның кушымта итеп бирелгән Программасын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Урыссу авыл җирлеге башлыгы ИНН 1642004850 Ф.Г. Әминова

Урыссу авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына кушымта
20.12.2021 ел №20

## Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә 2022 елга муниципаль контроль буенча закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасы

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2022 елга муниципаль контроль буенча закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын кисәтүнең әлеге программасы (алга таба - Программа) оешмалар һәм гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәүне стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуларга һәм (яисә) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерә ала торган шартларны, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерергә мөмкин булган сәбәпләрне һәм факторларны бетерү, аларны үтәүнең ысуллары турында мәгълүматлаштыруны арттыру максатларында эшләнде.

Әлеге Программа Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан эшләнгән һәм үтәлергә тиеш.

### 1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның агымдагы торышына анализ, контроль органның профилактик эшчәнлеген агымдагы үстерүнең тасвирламасы, Программа юлланган проблемаларга характеристика

1.1. Муниципаль контроль төре: төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль.

1.2. Муниципаль контроль предметы булып Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 12.07.2021 ел, № 6 карары белән расланган юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтә алырлык булуын тәэмин итү таләпләрен үтәү тора.

Шулай ук контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның үтәлеше муниципаль контроль предметы булып тора.

### 2. Программаны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары

2.1. Профилактика эшенең максатлары түбәндәгеләр:

барлык контрольдә тотыла торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәүне стимуллаштыру;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) салуга китерергә мөмкин булган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

3) мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотылучы затларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүматлаштыруны арттыру;

4) контрольдә тотыла торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару;

5) контрольдә тотыла торган затларга административ йөкләнешне киметү;

6) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә китерә торган зыян күләмен киметү.

2.2. Профилактика эшенең бурычлары түбәндәгеләр:

мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау системасын ныгыту;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуларга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү;

3) карала торган хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә оешмаларның һәм гражданнарның хокукый аңын һәм хокукый культурасын арттыру.

Тикшерелә торган намуслы контрольдә тотыла торган затларны матди булмаган бүләкләүгә юнәлдерелгән чараларны контрольдә тоту рәвешендәге хәлдә программада намуслылыкны стимуллаштыру чаралары каралмаган.

Мәҗбүри таләпләрне үтәүне мөстәкыйль бәяләү рәвеше турындагы нигезләмәдә (үз-үзеңне тикшерү) каралмаган, димәк, программада үз-үзеңне тикшерү ысуллары автоматлаштырылган режимда билгеләнмәгән ("Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 51 маддәсенең 1 өлеше).

3. Профилактика чаралары исемлеге, аларны үткәрү сроклары (вакыты)

| № т/б | Чара исеме | Чараны гамәлгә ашыру срогы | Җаваплы вазифаи зат |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәгълүмат бирү. Мәгълүмат бирү Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында тиешле белешмәләрне урнаштыру юлы белән мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла | Даими | Авыл җирлеге башлыгы |
| 2. | Хокук куллану практикасын гомумиләштерү. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү үткәрелгән контроль чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны җыю һәм анализлау юлы белән Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад әзерли, ул контроль органы житәкчесе тарафыннан раслана | Ел саен хокук куллану практикасын гомумиләштерү елыннан соңгы елның 30 гыйнварыннан да соңга калмыйча Хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү | Авыл җирлеге башлыгы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Кисәтү белдерү.<br>Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү Башкарма комитетта мәҗбүри таләпләрне бозулар турында белешмәләр булган очракта һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган мәнфәгатьләргә зыян (зарар) китергән дип расланган очракта контрольлек итүче затка игълан ителә | Законнарда каралган нигезләр барлыкка килгән саен | Авыл җирлеге башлыгы |
| 4. | Консультация бирү.<br>Консультация бирү профилактик чара, контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрү барышында телдән яисә язма рәвештә телефон аша, видео-конференц-элемтә аша, шәхси кабул итүдә гамәлгә ашырыла. | Контрольдәге затлар һәм аларның вәкилләре мөрәҗәгатьләре буенча даими рәвештә | Авыл җирлеге башлыгы |
| 5. | Профилактик визит | Елына бер тапкыр | Авыл җирлеге башлыгы |

4. Программаның эффектлылыгы һәм нәтиҗәлелеге күрсәткечләре

| № т/б | Күрсәткеч исеме | Күләме |
|---|---|---|
| 1. | «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2021 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырылган | 100% |
| 2. | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган докладны раслау, аны бастырып чыгару | Башкарылмаган / үтәлмәгән |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Мәҗбүри таләпләрне әзерләнә торган хокук бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне бозуның билгеләре турындагы расланган белешмәләр белән мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча бирелгән кисәтүләр өлеше һәм мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китергән йә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудырган дип расланган белешмәләр булмаган очракта (%) | 20% һәм аннан да күбрәк |
| 4. | Консультация алуга мөрәҗәгать иткән затларның гомуми санына консультация бирүдән канәгать булган затлар өлеше | 100% |